МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.03.2020 г.Казань № 215

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 17 апрелендә 6620 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында к а р а р и т ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.А. Зарипова

2020 елның 31мартыннан 215 санлы
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин һәм
социаль яклау министрлыгы
боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә аерым административ
регламентларга кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 7 апрелендәге «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга ел саен акчалата түләү билгеләү» турындагы 212 санлы боерыгындагы «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга ел саен акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 7 июнендәге 317 санлы, 2016 елның 30 июнендәге 371 санлы, 2017 елның 8 июнендәге 349 санлы, 2018 елның 15 маендагы 365 санлы, 2018 елның 24 сентябрендәге 897 санлы, 2019 елның 7 маендагы 323 санлы, 2019 елның 19 августындагы 636 санлы, 2019 елның 13 ноябрендәге 1001 санлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән):

1 бүлектә:

1.4.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренә (алга таба – КФҮ) һәм (яки) КФҮнең читтән торып эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә»;

5.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 елның 21 июнендәге 539 санлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 51, 1733 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланды»;

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» 2.4. бүлегендәге өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчегә еллык акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү ел саен акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла»;

2.5 бүлекнең «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

алтынчы абзацта «Үзәкнең бүлеге» сүзләреннән соң «КФҮтә, читтән торып эшләү урынында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Гаризалар һәм документлар КФҮ аша яисә КФҮнең читтән торып эш урыны аша бирелә ала.»;

2.15 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

алтынчы абзацта «электрон рәвештә» сүзләреннән соң «КФҮ аша, КФҮнең читтән торып эш урыны аша» сүзләрен өстәргә;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КФҮләрдә, КФҮнең читтән тырып эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми»;

уналтынчы абзацта «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләреннән соң , «КФҮтә, КФҮнең читтән торып эш урынында» дип өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Мөрәҗәгать итүченең КФҮкә, КФҮнең читтән торып эш урынында мөрәҗәгатендә, гариза һәм документларны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча Үзәк бүлекчәсенә тапшыру тәэмин ителә.»

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең һәм КФҮнең дәүләт хезмәте күрсәткәндә үзара хезмәттәшлеге тәртибе «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – үзара хезмәттәшлек турында килешү) арасында, шулай ук КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр - КФҮ эше Регламенты белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен җайга сала.»;

5 бүлектә:

5.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә, КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.»;

5.3 пунктта:

«дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесе» сүзләреннән соң, беренче абзацта «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» дип өстәргә;

«(http//mtsz.tatarstan.ru/)» сүзләреннән соң икенче абзацны «КФҮнең рәсми сайты(http://mfc16.tatarstan.ru)» сүзләрен өстәргә;

5.4 пунктта «дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта:

икенче абзацта «дәүләт хезмәткәре (учреждение хезмәткәре)» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «дәүләт хезмәткәре (учреждение хезмәткәре)» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «яисә дәүләт хезмәткәре» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

5.7.1 пунктында «дәүләт хезмәтен күрсәтүче» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

6 бүлекне түбәндәге эчтәлекле белән тулыландырырга:

«6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре»

6.1. КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтеләсе гариза һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү;

3) гариза һәм документларны үзәк бүлекчәсенә җибәрү.

6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

Мөрәҗәгать итүче КФҮләргә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтен алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче http://mfc16.tatarstan.ru адресы буенча КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында бирелгән мәгълүмат тора.

6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтеләсе гариза һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә, документларын кушып, КФҮкә яисә КФҮнең читтән торып эшләү урынына дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә.

6.3.2. Гаризалар һәм документлар кабул итүче КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе булып кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар тора.

6.4. Гариза һәм документларны үзәк бүлекчәсенә җибәрү.

КФҮ белгече гариза һәм документларны үзәк бүлегенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Үзәк бүлегенең һәм КФҮнең үзара хезмәттәшлек итү тәртибе, ә КФҮкә мөрәҗәгать итүчеләр КФҮнең эш регламенты белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, әмма КФҮтә гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, Үзәк бүлегенә гариза һәм документлар җибәрү тора.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша күпфункцияле үзәккә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзәк бүлеге биргән карарда җибәрелгән хаталарны төзәтү турында язмача гариза бирә.

Гаризалар кабул итүче КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура КФҮ эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Үзәк бүлегенә җибәрү.

КФҮ белгече техник хаталарны төзәтү турында гаризаны Үзәк бүлегенә хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин КФҮтә гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе булып Үзәк бүлекчәсенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү тора.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 27 июлендәге «Иректән мәхрүм итү рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән затларга психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүри дәвалану урынына һәм аннан соң реабилитацияләнгән затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү» буенча 604 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүри дәвалануга урын һәм аннан соң реабилитацияләнгән затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында, (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 25 февраленнән 102 санлы, 2015 елның 12 ноябрендәге 830 санлы, 2016 елның 7 июнендәге 317 санлы, 2017 елның 8 июнендәге 350 санлы, 2017 елның 1 декабрендәге 843 санлы, 2018 елның 15 маендагы 366 санлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 886 санлы, 2019 елның 20 июнендәге 487 санлы, 2019 елның 3 сентябрендәге 663 санлы, 2019 елның 12 ноябрендәге 987 санлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

1 бүлектә:

1.4.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренә (алга таба – КФҮ) һәм (яки) КФҮнең читтән торып эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.»;

5.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында «2012 елның 21 июнендәге 539 санлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 51, 1733 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланды.»;

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» 2.4. бүлегендәге дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.5 бүлекнең «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

беренче абзацта «кредит оешмасы» сүзләреннән соң «федераль законнар нигезендә социаль түләүләр алу өчен» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацта «Үзәкнең бүлекчәсенә» сүзләрен «КФҮтә яки КФҮнең читтән торып эш урынында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Гаризалар һәм документлар КФҮ аша яисә КФҮнең читтән торып эш урыны аша бирелә ала.»;

2.15 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

бишенче абзацта «электрон рәвештә» сүзләреннән соң «КФҮ аша, КФҮнең читтән торып эш урыны аша» сүзләре өстәргә;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КФҮләрдә, КФҮнең читтән тырып эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.»;

уналтынчы абзацта «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләреннән соң , «КФҮтә, КФҮнең читтән торып эш урынында» дип өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Мөрәҗәгать итүченең КФҮкә мөрәҗәгатендә, КФҮнең читтән торып эш урынында гариза һәм документларны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча Үзәк бүлекчәсенә тапшыру тәэмин ителә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең һәм КФҮнең дәүләт хезмәте күрсәткәндә үзара хезмәттәшлек тәртибе «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – үзара хезмәттәшлек турында килешү) арасында, шулай ук КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр - КФҮ эш Регламенты белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен җайга сала.»;

5 бүлектә:

5.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә, КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.»;

5.3 пунктта:

«дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесе» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре өстәргә;

«(http//mtsz.tatarstan.ru/)» сүзләреннән соң икенче абзацны «КФҮнең рәсми сайты(http://mfc16.tatarstan.ru)» сүзләрен өстәргә;

5.4 пунктта «дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең) вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре өстәргә;

5.5 пунктта:

икенче абзацта «дәүләт хезмәткәре (учреждение хезмәткәре)» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «дәүләт хезмәткәре (учреждение хезмәткәре)» сүзләреннән соң « КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре өстәргә;

бишенче абзацта «дәүләт хезмәткәре (учреждение хезмәткәре)» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре өстәргә;

5.7.1 пунктында «дәүләт хезмәтен күрсәтүче» сүзләреннән соң «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә;

6 бүлекне түбәндәге эчтәлекле белән тулыландырырга:

«6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре»

6.1. КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтеләсе гариза һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү;

3) гариза һәм документларны үзәк бүлекчәсенә җибәрү.

6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

Мөрәҗәгать итүче КФҮләргә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтен алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче http://mfc16.tatarstan.ru электрон адресы буенча КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында бирелгән мәгълүмат тора.

6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтеләсе гариза һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә, документларын кушып, КФҮкә яисә КФҮнең читтән торып эшләү урынына дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә.

6.3.2. Гаризалар һәм документлар кабул итүче КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе булып кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар тора.

6.4. Гариза һәм документларны үзәк бүлекчәсенә җибәрү.

КФҮ белгече гариза һәм документларны үзәк бүлегенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Үзәк бүлегенең һәм КФҮнең үзара хезмәттәшлек итү тәртибе, ә КФҮкә мөрәҗәгать итүчеләр - КФҮ эше регламенты белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, әмма КФҮтә гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, Үзәк бүлегенә гариза һәм документлар җибәрү тора.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризалар кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша күпфункцияле үзәккә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге биргән карарда җибәрелгән хаталарны төзәтү турында язмача гариза бирә.

Гаризалар кабул итүче КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура КФҮ эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гаризалар тора.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Үзәк бүлегенә җибәрү.

КФҮ белгече техник хаталарны төзәтү турында гаризаны Үзәк бүлегенә хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин КФҮтә гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе булып Үзәк бүлекчәсенә техник хаталарны төзәтү турында гаризалар җибәрелү тора.